**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**АТНИНСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ**

422750, село Большая Атня, улица Советская, дом 38

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ӘТНӘ РАЙОН СОВЕТЫ**

422750, Олы Әтнә авылы, Совет урамы., 38нче йорт

Тел.: 8(84369)21004, факс: 8(84369)21020, E-mail: atnya@tatar.ru, сайт: atnya.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ КАРАР

19 февраль 2024ел. № 219

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районының «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законга, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Уставына ярашлы рәвештә, ачык тыңлаулар протоколын һәм Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү проекты буенча ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында 2023 елның 08 декабрендәге нәтиҗәне, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Кулле Кими авыл җирлегенең 23.01.2024 елның 10-53/635 номерлы генераль планына үзгәрешләр кертү проектына нәтиҗәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советы **карар итте:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының 15.11.2019 № 174 карары белән расланган Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Кулле-киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең генераль планына үзгәрешләр кертергә.
2. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Күлле-Киме авыл җирлегенә «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Күлле-Киме авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү турында»гы карарны территориаль планлаштыру Федераль дәүләт мәгълүмат системасының (https://fgistp.economy.gov.ru) рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.
3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының (www.pravo.tatarstan.ru) рәсми хокукый мәгълүмат порталында һәм ТР Әтнә муниципаль районының (www.atnya.tatarstan.ru) рәсми сайтында бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә)
4. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көннән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Советының Җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек, законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Әтнә муниципаль районы Башлыгы-
район Советы Рәисе Г.Г.Хәкимов